4. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 29 сент., 15 сәг. 30 мин.
5. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 3 ноябрь, 15 сәг. 30 мин.
6. Юлчы / Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе. 2018. 2 декабрь, 15 сәг. 30 мин.

**Ф.Р. Сибгаева**
доцент
Казанский (Приволжский) федеральный университет
*г. Казань, Россия*
© Ф.Р. Сибгаева

## БАСМА МАТБУГАТТА ТӘЭСИР ИТҮ ФУНКЦИЯСЕН БЕЛДЕРҮДӘ ТОТРЫКЛЫ ГЫЙБАРӘЛӘРНЕҢ РОЛЕ

*Аннотация. Известно, что фразеологические единицы, также как и отдельные слова, по употреблению могут быть нейтральными и стилистически маркированными. Практика употребления языка в разных сферах общения людей выработала определенный набор языковых средств в соответствии с задачами каждого стиля. В языке средств массовой информации находит свое воплощение публицистический стиль. Для того чтобы воздействовать на массовое сознание, необходимы наиболее сильные и яркие языковые средства. Именно одним из таких средств можно считать фразеологические обороты. Фразеологизмы рассматриваются не как особая подсистема внутри словарного состава языка, а как набор специфических лексических единиц, органически связанных со всей системой лексики, включенных в общую сеть системных семантических связей ее единиц. Специфика фразеологизмов заключена в их форме, а не в особенностях положения в общей системе лексики. Место это определяется семантической значимостью отдельных фразеологизмов, семантическими связями с другими единицами.*

*Ключевые слова: фразеологическая единица, текст, специфическая лексика, язык средств массовой информации, публицистический стиль.*

*Abstract. It is known that phraseological units, as well as individual words, can be neutral and stylistically marked in use. The*

*practice of using language in different areas of communication has developed a certain set of language tools in accordance with the objectives of each style. In the language of the mass media, the journalistic style is embodied. In order to influence the mass consciousness, the most powerful and vivid language tools are needed. It is one of these tools that can be considered phraseological turns. Phraseological units are considered not as a special subsystem within the vocabulary of a language, but as a set of specific lexical units that are organically linked to the entire lexical system, included in the General network of system semantic connections of its units. The specificity of phraseological units lies in their form, not in the peculiarities of their position in the General system of vocabulary. This place is determined by the semantic significance of individual phraseological units, semantic connections with other units.*

*Key words: phraseological unit, the text-specific vocabulary, the language of the media, journalistic style.*

Заманча тикшеренүләрнең актуаль максаты – массакүләм мәгълүмат чараларының тел үзенчәлекләрен, публицистик текстларның тәэсир итү функциясен барлыкка китерүче чараларны, аларның төрләрен билгеләү, аларда кулланылган визуаль элементларның үзенчәлекләрен күрсәтү. Массакүләм мәгълүмат чаралары арасында газета аерылып тора. Бу газетаның мәгълүмат чаралары арасында бик борынгы бер чара булуы белән аңлатыла. Нәкъ менә газетада төп стилистик чаралар һәм алымнар формалашкан. Соңрак исә алар аудитория белән телдән аралашу формаларының башкаларына күчкән [Васильева 1982: 7]. Шулай итеп, Газета теле публицистик стильнең нигезен тәшкил итә.

Телнең кешегә, аның фикер йөртү рәвешенә һәм үз-үзен тотышына тәэсир итүе турыдан туры массакүләм мәгълүмат чаралары белән бәйле. Чыннан да, массакүләм мәгълүмат чараларына караган төп функцияләрнең берсе хәбәр итү булса, икенчесе – тәэсир итү. Дөнья вакыйгалары белән таныштырып һәм кешенең ял сәгатьләрен алып, массакүләм мәгълүмат чаралары аның фикер йөртүенә, дөньяны кабул итү стиленә, бүгенге көн мәдәнияте төренә тәэсир итәләр. Ә ышандыру һәм нәрсәгә дә булса теләк тудыру дөньяга бәя бирү аша башкарыла. Гомумтел категориясе буларак, бәя бирү телнең барлык өлкәләрендә, аеруча лексикада чагылыш таба.

Тел берәмлегенең бәя бирә алу үзлеге аның төп мәгънәсе түгел,  еш кына коннотатив мәгънәсе белән бәйле. Сүзнең лексик мәгънәсенә турыдан туры карамаса да, коннотация тасвирлана торган предметның бәя бирелгән образын укучыга тәкъдим итә. Шулай итеп, махсус бәя бирүче сүзләрне, гыйбарәләрне кулланмыйча, нәтиҗәле бәяләүгә булыша, димәк, укучылар аудиториясенә тәэсир итә.

Хәбәр итү функциясе публицистик стильгә караган түбәндәге үзенчәлекләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, дөреслек, рәсми бәян итү, объективлык, тотнаклылык. Тәэсир итү функциясе ачык, иҗтимагый бәяләнү һәм бәхәсләшүчәнлек, гадилек һәм аңлаешлы аңлату белән билгеләнә. Мәгълүмати жанрларга хәбәр итү функциясе хас булса, аналитик жанрларга тәэсир итү функциясе хас.

Газетта сурәтләү-бизәкләү чаралары белән эш итү үзенчәлекләрен фразеологизмнар мисалында киңрәк, күләмлерәк күрсәтергә була. Фразеологик әйтелмәләр газет теленең вакытлы (экспрессив) чаралары арасында аеруча әһәмиятлеләрдән. Алар газет сөйләмен ачык, төгәл, кыска итүдә дә, аңа җанлылык, сыгылмалылык бирүдә дә зур роль уйный» дип язган филология фәннәре докторы Илдар Низамов үзенең Журналист тексты телбизәксез була аламы?» мәкаләсендә. Татар вакытлы матбугатында тотрыклы гыйбарәләр башисем ролендә дә, язмаларның эчтәлеген баету өчен дә, композиция-сюжет мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендә дә файдалануга да мисаллар очрап тора. Мәсәлән:

***Чебеннән фил ясыйлар*** *(кабат яулык турында)* (Ватаным Татарстан», 01.01.2017);

*Бу юлы тагын нинди* ***мөгез чыгарырга*** *җыеналар?* (Ватаным Татарстан», 23.04.2019);

*Моның ише мәсьәләгә минем* ***теш үтми***. (Ватаным Татарстан», 11.06.2019);

*Хәзер бит техника һәм технологияләр ярдәмендә* ***колагына аю баскан*** *теләсә кемнән зур җырчы ясап була дип әйтәләр.* (Ватаным Татарстан», 11.06.2019);

*Хәрби хезмәттән чыныгып кайтуларын түземсезләнеп көтеп, улларының салкын гәүдәләрен тимер табутларда гына күреп калган кайбер ата-аналарның* ***йөрәкләре ничек чыдый икән****?!* (Татарстан яшьләре», 28.12.10);

*Күпме шәһәрләрдә һәйкәлләр карап йөреп, аналар хөрмәтенә куелганнарының **җанны болай әрнетә торганын** күрмәдем.* (Татарстан яшьләре», 25.12.10).

Әлеге мисаллардан күренгәнчә, фразеологизмнарны төрлечә үзгәртеп (аерым компонентларын кыскартып, яисә берәр мәгънәви яисә композицион кисәк өстәп (әйтик, тотрыклы гыйбарәнең бер компонентын – беренче яисә икенче өлешен генә – яртысын гына алу) юлы белән үзгәртеп куллану үрнәкләре чагылды. Мәсәлән: БДИ бердәйме?» мәкаләсенең авторы С.Кашапова *РФ мәгариф һәм фән министрлыгы **мәсьәләне менә шулай кабыргасы белән куйды»*** (Мәдәни Җомга», 8.05.09) җөмләсендә мәсьәләне кабыргасы белән кую» фразеологик берәмлегенә менә шулай» компонентын өстәп куя.

Р.Муллаянова Ольга әби бакчаларын сагына» язмасында *Әнә шундый очрашу вакыйгасы, хатирәләр Ольга әбинең **күңелен тәмам кузгатты»*** (Ватаным Татарстан», 3.04.09) җөмләсендәген күңел кузгату» фразеологизмындагы ике сүз арасына тәмам» берәмлеген өстәп куя.

Татар вакытлы матбугатында мондый мисалларны күпләп табарга була.

Журналистлар үз язмаларында фразеологизмнарның аерым компонентларын кыскартып та кулланалар. Мәсәлән, Ә. Фәйзрахманов *Марилар спектакльләрен урысча куялар. Бу инде **комга килеп терәлү** дигән сүз»* (Мәдәни Җомга, 19.12.08) җөмләсендә ***көймә комга килеп терәлгән*** фразеологизмы кыскартылып бирелгән.

Тотрыклы гыйбарәләрнең трансформацияләнүе аларның заманга җайлашуын күрсәтеп тора, фразеологизмнарны теге яки бу иҗтимагый-сәяси очракта уңышлы итә. Шулай итеп, төрле үзгәрешләр кичергән тотрыклы гыйбарәләр үзләренең эмоциональлеге һәм экспрессиясе белән укучыларга тәэсир итә.

Шулай итеп, массакүләм мәгълүмат чаралары хәбәр тарату максатын күздә тотып кына барлыкка килсәләр дә, бүгенге көндә мәгълүматны хәбәр дә итәләр, анализлыйлар да, дөнья сурәтен дә барлыкка китерәләр, күңел ачарга ярдәм итәләр. Өстәвенә, массакүләм мәгълүмат чараларының теләсә кайсы функциясе тәэсир итү белән бәйле булырга мөмкин. Теге яки бу вакыйга турында хәбәр итеп кенә калмыйча, җәмәгатьчелек фикерен

формалаштыру да аларның бурычы булып санала. Димәк, вакытлы матбугат – халык аңына тәэсир итүче мөһим бер чара.


Әдәбият:

1. Васильева А.Н. Газетно-публицистический стиль речи. – Москва: Русский язык,1982. – 205 с.
2. Гарифуллин В.З. Лингвостилистическая система татарского газетного текста: диссер. ... доктор. филол.наук. – Казань, 1998. – 427 с.
3. Низамов И.М. Матбугатның тәэсирле сүзе: газета лексикасы мәсьәләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 144 б.
4. Низамов И.М. Элгәрләр һәм ана теле // Йөз еллык матбугатыбыз: үткәне, бүгенгесе, киләчәге (фәнни-гамәли конференция материаллары). – Казан: Казан ун-ты нәшр, 2005. – 37–43 б.



***А. Ю.* Сысоева**

магистрант

Казанский (Приволжский) федеральный университет

*г. Казань, Россия*



© А. Ю. Сысоева


## ЖУРНАЛИСТИКА ЧЕРЕЗ ПРИЗМУ СОЦИАЛЬНЫХ СЕТЕЙ

Современный мир – это максимальное количество взаимоотношений, деловые партнёры и быстрый процесс передачи информации. Социальные сети, такие как кроссплатформенный мессенджер «Telegram», приложение для обмена фотографиями и видеозаписями «Instagram» встали в один ряд с журналистами, и активно ведут и свою деятельность распространителей информации – у них так же, как и у средств массовой информации, есть и собственные источники информации и возможность совершенно спокойно позвонить представителю организации, и попросить официальный комментарий. Однако, издания и журналисты не уступают и сами создают аккаунты в социальных сетях. В нашей работе мы рассмотрим как это происходит в реалиях средств массовой информации Республики Татарстан.

Отметим, что в Республике Татарстан на социальные сети обращают внимание особенно – начиная от Президента Республики